ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ
КОНСТИТУЦИЯ СУДЫ
**БИЛГЕЛӘМӘСЕ**

**Татарстан Республикасы Җир кодексының 32 статьясы белән үзенең конституциячел хокуклары һәм ирекләре бозылуга карата гражданин Р.К. Галимов шикаятен карауга алудан баш тарту турында**

Казан шәһәре 2017 елның 10 июле

Татарстан Республикасы Конституция суды, Рәисе Ф.Г. Хөснетдинов, судьялары Ф.Р. Волкова, Л.В. Кузьмина, Э.М. Мостафина, Р.Г. Сәхиева, А.Р. Шакараев составында,

суд утырышында «Татарстан Республикасы Конституция суды турында» Татарстан Республикасы Законының 44 статьясы нигезендә гражданин Р.К. Галимов шикаятен алдан өйрәнгән судья А.Р. Шакараев бәяләмәсен тыңлаганнан соң

**ачыклады:**

1. Татарстан Республикасы Конституция судына гражданин Р.К. Галимов Татарстан Республикасы Җир кодексының 32 статьясы белән үзенең конституциячел хокуклары һәм ирекләре бозылуга карата шикаять белән мөрәҗәгать итте.

Дәгъвалана торган норма дәүләт милкендәге яисә муниципаль милектәге җир кишәрлекләрен гражданнар һәм юридик затлар милкенә бирү мәсьәләләрен җайга сала, шул исәптән шундый җир кишәрлекләрен түләүсез бирү очракларын билгели.

Шикаятьтән һәм аңа кушымта итеп бирелгән документлар күчермәләреннән аңлашылганча, мөрәҗәгать итүче — 1988 елда Чернобыль АЭСында һәлакәт салган зыяннарны бетерүдә катнашучы. Гражданин

Р.К. Галимов билгеләгәнчә, ул торак шартларын яхшыртуга мохтаҗ һәм «Чернобыль АЭСындагы һәлакәт аркасында радиация йогынтысына дучар булган гражданнарны социаль яклау турында» 1991 елның 15 маендагы 1244-1 номерлы Россия Федерациясе Законының 14 статьясындагы беренче өлешенең 8 пункты нигезендә индивидуаль торак төзелеше өчен, аның фикеренчә, аңа түләүсез бирелергә тиешле җир кишәрлеге белән чираттан тыш тәэмин ителергә хокуклы.

Шуңа бәйле рәвештә гражданин Р.К. Галимов Казан шәһәре муниципаль берәмлеге Башкарма комитетының Җир һәм мөлкәт мөнәсәбәтләре комитетына аңа, Чернобыль АЭСында һәлакәт салган зыяннарны бетерүдә катнашучы буларак, индивидуаль торак төзелеше өчен җир кишәрлеген түләүсез һәм чираттан тыш тәртиптә бирү турында гариза белән мөрәҗәгать иткән. Ләкин Татарстан Республикасында Чернобыль АЭСында һәлакәт салган зыяннарны бетерүдә катнашучыларга җир кишәрлекләрен бирү тәртибен җайга сала торган норматив хокукый базаның булмавына сылтама ясалып, мөрәҗәгать итүчегә җир кишәрлеген бирүдән баш тартылган.

Гражданин Р.К. Галимов санавынча, федераль закон чыгаручы Россия Федерациясе Җир кодексының 39.5 статьясындагы 7 пунктчасында дәүләт милкендәге яисә муниципаль милектәге җир кишәрлеге милек итеп Россия Федерациясе субъектлары законнарында каралган очракларда әлеге статьяның 6 пунктчасында күрсәтелмәгән башка гражданнарның аерым категорияләренә вәкаләтле орган карары нигезендә түләүсез бирелә дип билгеләп, Россия Федерациясе субъекты закон чыгаручысына тиешле хокукый җайга салуны гамәлгә ашыру, шул исәптән «Чернобыль АЭСындагы һәлакәт аркасында радиация йогынтысына дучар булган гражданнарны социаль яклау турында» Россия Федерациясе Законы нигезендә аларга хокуклары булган гражданнар категорияләренә җир кишәрлекләрен бирү тәртибен урнаштыру вәкаләтен тапшырган.

Шул ук вакытта, мөрәҗәгать итүче күрсәткәнчә, Татарстан

Республикасы закон чыгаручысы Татарстан Республикасы Җир кодексының 32 статьясында дәүләт милкендәге яисә муниципаль милектәге җир кишәрлекләрен гражданнар һәм юридик затлар милкенә түләүсез бирү очракларын билгеләп, «Чернобыль АЭСындагы һәлакәт аркасында радиация йогынтысына дучар булган гражданнарны социаль яклау турында» Россия Федерациясе Законы нигезендә аларга хокуклары булган гражданнар категорияләренә җир кишәрлекләрен бирү мөмкинлеген күздә тотмаган, шуның белән аның конституциячел хокукларын бозган.

Моннан тыш, мөрәҗәгать итүче фикеренчә, җир кишәрлекләре белән чираттан тыш тәэмин итү, Казан шәһәре муниципаль берәмлеге Башкарма комитетының Җир һәм мөлкәт мөнәсәбәтләре комитеты җавапларында тәкъдим ителгәнчә, аукционда гамәлгә ашырыла алмый.

Бәян ителгәннәр нигезендә гражданин Р.К. Галимов Татарстан Республикасы Конституция судыннан Татарстан Республикасы Җир кодексының 32 статьясын Татарстан Республикасы Конституциясенең 28 (беренче һәм икенче өлешләр), 29 (беренче өлеш), 32, 54 (беренче өлеш), 55 һәм 58 статьяларына туры килми дип тануны сорый.

2. Җир законнарының төп принципларын билгеләп, Россия Федерациясе Җир кодексы шул исәптән җирдән файдалануның түләүлелеге принцибын бүлеп чыгара, аның буенча, федераль законнар һәм Россия Федерациясе субъектлары законнары билгеләгән очраклардан тыш, җирдән теләсә нинди файдалану түләүле башкарыла (1 статьяның 1 пунктындагы 7 пунктчасы).

2015 елның 1 мартыннан дәүләт милкендәге яисә муниципаль милектәге җир кишәрлеген гражданнар һәм юридик затлар милкенә түләүсез бирү очраклары Россия Федерациясе Җир кодексының 39.5 статьясы белән билгеләнгән. Шул ук вакытта Россия Федерациясе Җир кодексы үзе, башка федераль законнар кебек үк, андый очрак буларак Чернобыль АЭСында һәлакәт салган зыяннарны бетерүдә катнашучыларга индивидуаль торак төзелеше өчен җир кишәрлеген түләүсез нигездә бирүне күздә тотмый.

«Чернобыль АЭСындагы һәлакәт аркасында радиация йогынтысына дучар булган гражданнарны социаль яклау турында» 1991 елның 15 маендагы 1244-1 номерлы Россия Федерациясе Законының 15 статьясы нигезләмәләренең 14 статьясындагы 1 өлешенең 8 пункты белән үзара бәйләнештә сүзгә-сүз эчтәлегеннән аңлашылганча, федераль законнар гражданнарның карала торган категориясенә торак шартларын яхшыртуга мохтаҗлык булганда җир кишәрлекләре белән тәэмин ителүгә өстенлекле (чираттан тыш) хокукны гына гарантияли.

Шундый шартларда Татарстан Республикасы Җир кодексының 32 статьясында Чернобыль АЭСында һәлакәт салган зыяннарны бетерүдә катнашучыларны дәүләт милкендәге яисә муниципаль милектәге җир кишәрлеген түләүсез алу мөмкинлеге бирелгән затлар исәбендә күрсәтүнең булмавы үзеннән-үзе гражданнарның, шул исәптән мөрәҗәгать итүченең дә конституциячел хокукларын һәм ирекләрен бозу дип санала алмый, чөнки андый мөмкинлекне бирү өстәмә социаль ярдәм чарасы булып тора, аны билгеләү Татарстан Республикасының бурычы түгел, ә хокукы булып тора һәм әлеге социаль-икътисади үсеш этабында булган финанс һәм башка материаль мөмкинлекләргә бәйле.

Мондый нәтиҗә Россия Федерациясе Конституция Суды позициясенә дә туры килә, ул Россия Федерациясе Конституциясенең җир кишәрлекләрен түләүсез бирүне гарантияләмәве турында берничә мәртәбә искәртте (2009 елның 15 гыйнварындагы 105-О-О номерлы, 2011 елның 24 февралендәге 163-О-О номерлы һ.б. билгеләмәләр). Россия Федерациясе Конституциясенең 10 һәм 72 (1 өлешнең «в», «ж» пунктлары) статьялары, шулай ук Россия Федерациясе Җир кодексының 2015 елның 1 мартына кадәр гамәлдә булган 28 статьясындагы 2 пункты нигезендә җирне түләүсез бирү өчен нигезләрне, затлар даирәсен һәм шартларны билгеләү федераль закон чыгаручы һәм Россия Федерациясе субъекты закон чыгаручысы компетенциясенә керә, күрсәтелгән мәсьәләне хәл иткәндә алар җитәрлек дәрәҗәдә киң карамак ирегенә ия (2012 елның 22 мартындагы

523-О-О номерлы, 2013 елның 25 февралендәге 193-О номерлы, 2013 елның 21 ноябрендәге 1831-О номерлы, 2013 елның 24 декабрендәге 2134-О номерлы, 2015 елның 24 мартындагы 582-О номерлы билгеләмәләр).

Шулай итеп, дәгъвалана торган нормада мөрәҗәгать итүче күрсәткән аспектта нинди дә булса билгесезлек юк, шуңа бәйле рәвештә «Татарстан Республикасы Конституция суды турында» Татарстан Республикасы Законының 46 статьясындагы беренче өлешенең 2 пункты белән үзара бәйләнештә 39 статьясындагы икенче өлешенең 1 пункты нигезендә гражданин Р.К. Галимов шикаяте карала алмый. Югарыда аталган хокук бирелгән гражданнар категорияләре исемлеген киңәйтү, мөрәҗәгать итүче шуңа басым ясый да, гамәлдәге җир законнарына үзгәрешләр кертүне күздә тота, бу исә закон чыгаручы компетенциясенә керә һәм Татарстан Республикасы Конституция судының «Татарстан Республикасы Конституция суды турында» Татарстан Республикасы Законының 3 статьясында билгеләнгән вәкаләтләренә керми.

Мөрәҗәгать итүченең гражданнарга җир кишәрлекләрен чираттан тыш тәртиптә бергәндә сатулашу үткәрүнең законсыз булуы турындагы дәлилләренә килгәндә, шуны билгеләп үтәргә кирәк: әлеге мәсьәләләр Россия Федерациясе Җир кодексының V.1 бүлеге, аерым алганда, 39.6 статьясы белән җайга салына, аның нигезендә җир кишәрлекләрен чираттан тыш алу хокуклары булган гражданнарга җир кишәрлекләре сатулашу үткәрелмичә арендага бер тапкыр гына бирелә.

Шул ук вакытта федераль законнарның күрсәтелгән нормаларының конституциячеллеген тикшерү, гражданин Р.К. Галимов мөрәҗәгатьләрен караганда хокук куллану органнары кабул иткән карарларның нигезле, шул исәптән аңа җир кишәрлеген бирүдән баш тартуның законлы булу-булмавын бәяләү кебек, Татарстан Республикасы Конституция суды компетенциясенә шулай ук керми.

Бәян ителгәннәрдән чыгып һәм «Татарстан Республикасы Конституция суды турында» Татарстан Республикасы Законының 3 статьясына,

39 статьясындагы икенче өлешенең 1 пунктына, 46 статьясындагы беренче өлешенең 1 һәм 2 пунктларына, 66 статьясындагы бишенче өлешенә, 67 статьясындагы беренче һәм икенче өлешләренә, 69, 72, 73 һәм 101 статьяларына таянып, Татарстан Республикасы Конституция суды

**билгеләде:**

1. Татарстан Республикасы Җир кодексының 32 статьясы белән үзенең конституциячел хокуклары һәм ирекләре бозылуга карата гражданин Р.К. Галимов шикаятен карауга алудан баш тартырга, чөнки шикаять «Татарстан Республикасы Конституция суды турында» Татарстан Республикасы Законы билгеләгән таләпләр нигезендә карала алмый, ә мөрәҗәгать итүче куйган мәсьәләләрне хәл итү Татарстан Республикасы Конституция суды карамагына керми.

2. Бу шикаять буенча Татарстан Республикасы Конституция суды Билгеләмәсе катгый һәм аңа карата шикаять бирелми.

3. Әлеге Билгеләмәнең күчермәсен гражданин Р.К. Галимовка, Татарстан Республикасы Дәүләт Советына һәм Казан шәһәре муниципаль берәмлеге Башкарма комитетына җибәрергә.

4. Әлеге Билгеләмә «Татарстан Республикасы Конституция суды хәбәрләре»ндә басылып чыгарга тиеш.

**№ 30-О**

**Татарстан Республикасы**
**Конституция суды**